| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**26.09.2017** **г. Казань** **№ № 2174-р**

**«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы, “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының 24.18 статьясы нигезендә:

1. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак һәм торак булмаган күчемсез милек объектларының (җир кишәрлекләреннән тыш) дәүләт кадастр бәясе нәтиҗәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2014 ел, 24 ноябрь, 2572-р карарына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 ел, 13 февраль, 279-р, 2017 ел, 21 апрель, 894-р, 23 июнь, 1388-р, 22 август, 1923-р карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге эчтәлекле 4нче пункт белән тулыландырып, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«4. “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 1998 ел, 29 июль, 135-ФЗ Федераль законының 24.18 статьясында каралган дәүләт кадастр бәяләве үткәргәндә кулланылган белешмәләрнең дөрес булмавы нигезле әлеге карарга кертелгән һәм тиешле салым буенча салым базасын билгеләгәндә салым түләүчеләрнең хәлен яхшыртучы үзгәрешләр 2014 елның 1 гыйнварыннан соң булган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адресындагы рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Р.Мерзакреевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**